Муниципальное автономное общеобразовательное учреждение

«Усть-Туркская средняя общеобразовательная школа»

Бажуковский филиал

| РАССМОТРЕНО | СОГЛАСОВАНО | УТВЕРЖДЕНО |
| --- | --- | --- |
| Руководитель ШМО | Заместитель директора по УВР | Директор МАОУ «Усть-Туркская СОШ» |
| ______/ Муртазина | ________/ Аитова Э.Р. | ________/ Юсупова И.Ф. |
| Протокол №1 от «31» августа 2023 г. | «31» августа 2023 г. | Приказ №100 от «31» августа 2023 г. |

**РАБОЧАЯ ПРОГРАММА ПО ЛИТЕРАТУРНОМУ ЧТЕНИЮ**

**ДЛЯ ОБУЧАЮЩИХСЯ 3 КЛАССА**

**С УМСТВЕННОЙ ОТСТАЛОСТЬЮ**

Составитель: Шавалиева З.А.

## АҢЛАТМА ЯЗУЫ

Әдәби укудан 3 нче сыйныф укучылары өчен төзелгән программа дәүләт стандартларының федераль компонентына, гомуми белем бирү федераль дәүләт стандартларына нигезләнеп төзелде . Программа стандартның эчтәлеген җентекләп ачып бирә, стандарт таләп иткән күләмдә татар балаларына татар әдәбиятын укытуның гомуми юнәлешләрен билгели, предмет чаралары белән укучыларны тәрбияләү юлларын, аларның әдәби үсеш дәрәҗәсен билгели.

Күпмилләтле аудиториядә татар әдәбиятын укыту өчен төзелгән программа бербөтен документ булып тора, ул биш өлешне иңли:аңлатма язуы; укыту курсының эчтәлеге, укыту-тематик планы; укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр; курсның укыту-методик тәэмин ителеше өчен әдәбият исемлеге.

Әдәбият һәр яктан үскән, рухи яктан бай, әхлакый идеаллары һәм эстетик таләпләре булган камил шәхес тәрбияләүдә әһәмиятле урын алып тора. Башлангыч белем бирү системасындагы соңгы баскычларында татар әдәбияты курсы сәнгатьне тормыш белән бәйләп өйрәнүне, эчтәлек белән форма берлеге, тарихилык, традиция һәм новаторлык, тарихи-культурологик мәгълүматларны аңлау, әхлакый-эстетик күзаллау булдыру, әдәбият теориясе һәм тарихы буенча төшенчәләрне үзләштерү, әдәби әсәрне бәяләү күнекмәләрен формалаштыру, әдәби телнең сәнгатьлелек чаралары белән танышуны үз эченә ала.

Федераль дәүләт стандартларына нигезләнеп төзелгән татар әдәбияты дәреслекләре барлык фәннәрне өйрәнү барышындагы фундаменталь төшкә (фундаментальное ядрога), универсаль уку гамәлләренә нигезләнә, укучыларның яшь һәм әдәби үсеш дәрәҗәсен исәпкә ала. Укыту һәм тәрбиянең гомуми нәтиҗәләре иҗтимагый, шәхси, танып-белү һәм коммуникатив үсешне тәэмин итеп, укучыларның белемнәрен, күнекмәләрен үстереп, дөньяны танып белүгә әзерләп, хезмәттәшлеккә, үзлегеннән белем алуга, камиллеккә омтылучы шәхес тәрбияләүгә барып тоташа. Аерым алганда, уку-укытуга системалы-гамәли якын килү нәтиҗәсендә, укучыларның иҗтимагый үсешенә (халыкның рухи кыйммәтләрен аңлаучы, үстерүче Россия гражданины тәрбияләү); шәхси үсешенә (үзлегеннән белем алырга, иҗади сәләте үскән, компетентлы, үзаңы үскән, үзенең гражданлык карашларын ачыктан-ачык белдерүгә сәләтле, үз-үзенә тәнкыйди караштa торган, тормыш авырлыкларына каршы торырлык шәхес тәрбияләү); танып белү эшчәнлеген үстерүгә (фәнни дөнья сурәтен аңлаучы, үзенең танып-белү һәм интеллектуаль эшчәнлеге белән идарә итә ала торган, уку, белем алу чараларын күзаллый торган, репрезентатив, символик, логик, иҗади фикерләү сәләте үскән, рефлексиягә сәләтле укучы тәрбияләү); коммуникатив үсешкә (аралашу компетенциясе үскән, тыңларга, диалогта, гомуми сөйләшүдә катнаша алырлык, туган телен, рус телен, чит телне камил белүенә) басым ясалды. Шул ук гамәлләрне тормышка ашыру барышында, яшүсмерләрнең яшь үзенчәлекләре дә игътибарга алынды.

Күпмилләтле мохиттә гомуми әдәби белем бирү барышында универсаль уку гамәлләре дүрт блокка бүлеп карала. Алар арасында шәхси УУГ - тормышчан, шәхескә юнәлтелгән, һөнәри юнәлештә үз юлын табуга, кешенең эчке потенциалын рациональ файдалана белүенә бәйле блок. Регулятив уку гамәлләре шәхес тәрбияләүдә планлаштырырга өйрәтү, фаразлау, коррекция, бәяләү кебек якларны үзәккә ала.

Танып белү гамәлен алгы планга чыгарган блокта логик, проблеманы кую һәм чишүгә юнәлтелгән, тамга-символик якны иңләгән гомумуку гамәлләренә игътибар ителә. Коммуникатив УУГ кешеләр язмышына битараф булмауны, кешеләргә ярдәмчеллек сыйфатларын тәрбияләүне, иҗтимагый компетентлыкны үз эченә ала.

**Укыту предметына характеристика.**

Башлангыч мәктәп уку-укыту системасында 3 нче сыйныф әһәмиятле урын алып тора.

Дәреслек ике кисәктән тора. Укучыларның белем-күнекмәләрен бәяләп бару өчен, һәр кисәк тә дүртәр модульгә бүлеп төзелгән. Һәр модуль бөтен кисәкнең өлешләрен хәтерләтә. Модульгә салынган мәгълүмат та, дәреслек үзе дә хронологик нигезгә корыла. Шул ук вакытта модульләр эчендә тематик-хронологик принцип та саклана. Һәр модуль укучыларның әдәби үсеш дәрәҗәсен үстерүне дә, эрудициясен киңәйтүне дә, әдәбиятны сәнгатьнең башка төрләре белән бәйләп баруны да, теоретик төшенчәләрне үзләштерүне дә, сорау-биремнәрне үтәгәндә файдалана алуны да күздә тотып урнаштырылган. Дәреслектә модульләр арасындагы бәйләнешләр сорау-биремнәр һәм контроль тестлар аша гамәлгә куела. Шулай итеп, дәреслекне әдәби- теоретик төшенчәләр сүзлекчәсе, фразеологик сүзлекчә кебек белешмәләр төгәлли.

Федераль дәүләт стандартларына таянып, татар әдәбиятын өйрәнүнең максаты - туган халкының һәм җирле халыкның телен, мәдәниятен, әдәбиятын яхшы белгән, һәрьяктан камил, милли горурлык хисләре үскән шәхес (гражданин) тәрбияләү.

Әлеге максатны тормышка ашыру өчен, түбәндәге бурычлар билгеләнде:

-татар әдәбиятын, аның аеруча күренекле вәкилләре турында беренче күзаллау булдыру;

-әдәби әсәрне тыңлап һәм укып аңлау күнекмәләре булдыру;

- текст белән танышу, эчтәлеген сөйләп бирү күнекмәләрен формалаштыру,аны камилләштерә бару;
- әдәби текстларны дөрес, тиз һәм тора-бара сәнгатьле итеп укуларына ирешү;

Беренче баскычны тәшкил итүче 3 нче сыйныфта укучы балалар, шул рәвешле, халкыбызның бик бай әдәби мирас үрнәкләре белән таныша башлауның беренче адымнарыннан ук сүз сәнгатебезнең бик тә игелекле, тәэсирле йогынтысында яши, фикерле һәм шул үрнәкләрдә тәрбияләнәләр. Матур әдәбият белем һәм тәрбия бирүдә башка бер фән дә булдыра алмаган мөмкинлекләргә ия. Ул,барыннан да элек, милли үзаң тәрбияли. Бу исә аның үз халкының, туган иленең ихлас вәкиле булып формалашуына, ватанының тугрылыклы улы һәм кызы булып яшәүнең асыл мәгънәсен табигый рәвештә күңел хәзинәсе итеп әверелдерүенә китерә. Югарыда саналган бурычлар шушы олы максатка килүнең эзлекле баскычларын тәшкил итә. Программада тәкъдим ителгән әсәр текстларының күбесе балалар әдәбиятының һәм башка әдәби әсәрләрнеңиң яхшы үрнәкләреннән сайланып, табигать, кешенең табигатькә мөнәсәбәте, аның табигатьне саклаудагы роле, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр кебек бүгенге заман проблемаларына туры килә. Эчтәлеге 3 нче сыйныф укучыларына якын булган әкиятләр, мәзәкләр, табышмаклар,әйтемнәр укучыларда зирәклек, тапкырлык сыйфатлары тәрбияләүгә өлеш кертә. Программада уку һәм сөйләм үстерү, ятлау өчен әсәрләр,сөйләшү тематикасы кебек бүлекләр бирелгән.

«Рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәпләре өчен үрнәк программалар» (Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2011, 7-12,56-58 б.) һәм дәреслек "Башлангыч белем бирү федераль дәүләт стандарты"ның гомуми нигезләмәләренә туры килә. Анда дәүләт аккредитациясе булган мәгариф учреждениеләрендә бирелә торган башлангыч белемгә карата гомуми таләпләр бәян ителгән, Россия Федерациясенең төрле төбәкләрендә яшәүчеләрнең милли һәм мәдәни ихтыяҗларын күздә тотып төзелгән.

Ул түбәндәгеләрне истә тота:

-башлангыч сыйныф укучыларына башлангыч белемне сыйфатлы итеп алу өчен бердәй шартлар тудыра;

-укучының рухи-әхлакый үсешкә ирешүен һәм тәрбия алуын тәэмин итә;

-күп милләтле Россия халыкларының мәдәниятын сакларга һәм үстерергә ярдәм итә, туган телдә башлангыч белем алуга мөмкинлек тудыра, төрле милләтләрнең рухи кыйммәтләрен үзләштерергәҗирлек булдыра;

-укучының сәләтен һәм сәламәтлеген истә тотып оештырырга тиешле шартлар тудыра.

Укыту предметының укыту планында тоткан урыны 3нче сыйныфта ФДБС ның базис укыту планы буенча әдәби укуга сәгатьләр саны түбәндәгечә каралган: атнага 1 сәгать. Барысы -34 сәгать.

**Укытуның предмет, шәхси, метапредмет нәтиҗәләре**

Башлангыч белем бирү мәктәбендә әдәбиятны гамәли үзләштерү нәтиҗәсендә укучыларда татар әдәбиятының күп мәдәниятле дөньядагы роле һәм мөһимлеге турында күзаллаулар формалаша. Татар мәдәниятенең укучылар өчен булган катламы белән танышу мәдәнияткә карата ихтирам хисе уята, ягъни укучыларга үз мәдәниятләрен дә тирәнрәк аңларга мөмкинлек бирә, аларда ватанпәрвәрлек хисе уята.

Башлангыч гомуми белем бирү баскычында 3 нче сыйныфында татар әдәбиятына өйрәтүнең программада күрсәтелгән күләмдә предмет нәтиҗәләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

- аңлап һәм дөрес уку. Эчтән уку һәм сәнгатьле укуның башлангыч күнекмәләрен формалаштыру;
- текстның нәрсә турында булуын аңлата белү;
- укытучы ярдәмендә план төзү һәм шуның буенча текстның эчтәлеген сөйли белү;
- башка кеше укыганны тыңлап, эчтәлекне сөйли белү;
- әдәби әсәрләрне, сүзләрен дөрес әйтеп, йөгерек уку;
- авторның әйтергә теләгән фикерен аңлау, үз мөнәсәбәтен белдерү, өлешләргә бүлә һәм планын төзи белү;
- әдәби - теоретик төшенчәләрне рус әдәбият белеме белән тәңгәлләштерү;
- татар әдәбиятының дөнья культурасында тоткан урынын аңлау;
- 8 - 10 татар, рус шагыйрьләре исемнәрен һәм алар язган әсәрләрне белү;
- Казан һәм Татарстан төбәгендәге мәдәният учаклары (музей, театр, һ. б.), балалар матбугаты турында белү;
- 5 мәкаль, 5 әйтемне истә калдыру;
- мәкаль белән әйтем, фантастика белән әкият арасындагы аерманы белү;
- төрле авторларның 2 - 3 шигырен яттан сөйли белү;
- сүзлекләр, энциклопедияләр, Интернет-ресурслардан файдаланып, кирәкле материалны таба белү;
- төрле темаларга проект эше яклау;
- әдәби әсәргә, тормыш белән бәйләп, үз гамәлләренә бәя бирү Укытуның шәхси нәтиҗәләре

Башлангыч белем бирү баскычын тәгәлләгәндә, укучының үзенә һәм үзенең әйләнә-тирәсендәге кешеләргә, тормыштагы яшәеш проблемаларына карата түбәндәге шәхси кыйммәтләре формалашкан булуы күзаллана:

- шәхесара һәм мәдәниятара аралашуда татар теленә карата ихтирамлы караш булдыру һәм аны яхшы өйрәнү теләге тудыру;
- әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау;
- әдәби әсәрләрдәге төрле тормыш ситуацияләренә һәм геройларның гамәлләренә гомумкешелек нормаларыннан чыгып бәя бирү;

**Укытуның метапредмет нәтиҗәләре**

Башлангыч белем бирү баскычында татар әдәбиятын укыту, укучыларның фикер йөртү, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерүгә, шулай ук, реаль тормышта туган проблемаларны хәл итү өчен кирәк булган универсаль уку гамәлләрен (танып белү, регулятив, коммуникатив)формалаштыруга хезмәт итә.

Укучыларда мәгълүмати җәмгыятьтә яшәү һәм эшләү өчен кирәкле күнекмәләр үстерелә. Укучылар текст, күрмә-график рәсемнәр, хәрәкәтле яисә хәрәкәтсез сурәтләр, ягъни төрле коммуникацион технологияләр аша тапшырыла торган мәгълүмати объектлар белән эшләү тәҗрибәсе ала; презентацион материаллар әзерләп, зур булмаган аудитория алдында чыгыш ясарга өйрәнә; укучыларда, компьютер яисә ИКТ нең башка чаралары белән эш иткәндә, сәламәтлеккә зыян китерми торган эш алымнарын куллана алу күнекмәләре формалаша.

Танып белү нәтиҗәләре:

- фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дедуктив фикерли белү;
- иҗади һәм эзләнү характерындагы проблеманы билгеләү, аларны чишү өчен алгоритм булдыру;
- объектларны чагыштыру, классификацияләү өчен уртак билгеләрне билгеләү;
- төп мәгълүматны аеру, укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү;
- тиешле мәгълүматны табу өчен, энциклопедия, белешмәләр, сүзлекләр, электрон ресурслар куллану.

Регулятив нәтиҗәләр:

- уку хезмәтендә үзеңә максат куя, бурычларны билгели белү;
- эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра, нәтиҗәле эш алымнарын таба белү;
- уку эшчәнлеге нәтиҗәләрен контрольгә ала белү;
- билгеләгән критерийларга таянып, эш сыйфатына бәя бирә белү;
- укудагы уңышларның, уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый, анализлый белү;
- ихтыяр көче, максатчанлык, активлык кебек сәләтләрне формалаштыру;
- дәрескә кирәкле уку-язу әсбапларын әзерли һәм алар белән дөрес эш итә белү;
- дәрестә эш урынын мөстәкыйль әзерли белү һәм тәртиптә тоту күнекмәләрен үстерү.

Коммуникатив нәтиҗәләр:

- әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, аңа туры килерлек җавап бирә белү;
- әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төзү;
- аралаша белү сәләтен үстерү (аралашучанлык, хислелек, эмпатия хисләре);
- парларда һәм күмәк эшли белү;

**Укыту предметының төп эчтәлеге**

Укыту предметының эчтәлеге укучыларның яшь үзенчәлекләре буенча кызыксынуларын, аралашу ихтыяҗларын, психо-физиологик мөмкинлекләрен исәпкә алып сайлана; төп универсаль уку гамәлләрен үстерүгә, аларда шәхси кыйммәтләр формалаштыруга хезмәт итә һәм түбәндәгеләрне үз эченә ала.

Дәреслек ике кисәктән тора.

**Яңа стандарт куйган таләпләр.**

Базар икътисадының бүгенге таләпләре һәм мәгълүмати җәмгыятьнең тиз темплар белән формалашуы мәгариф системасы алдына яшь буынга белем бирү максатын һәм бурычларын, форма һәм эчтәлеген тамырыннан үзгәртү мәсьәләсен куйды. Мәгариф системасындагы яңалыкларны гамәлгә ашыруда төп көч вазифасын үтәү өчен икенче буын дәүләт стандартлары төзелә.

Икенче буын стандартларының нигезен яңа төр мөнәсәбәтләр тәшкил итә: бүген укучының билгеле бер белем дәрәҗәсенә ия булуын дәүләт кенә түгел, ә бәлки укучы, аның эти-әнисе дә дәүләттән билгеле бер күләмдә сыйфатлы белем бирүен таләп итү хокукына ия.

Ә хәзер башлангыч мәктәп өчен төзелгән яңа стандартларның төп характеристикасы белән танышып узыйк. Икенче буын стандартлары шәхес үсешен тәэмин итү, укытуга үз эшеңне төптән белеп якын килү бурычын куя. Башкача әйткәндә, мәгариф системасы баланы белемле итү хакында гына түгел, аңа күнекмәләр бирү, аны эшкә өйрәтү турында да кайгырта.

Яңа стандартларның тагын бер ягын ассызыклап үтәргә кирәк: аларда укучыга һәм укытучыга гына түгел, ә бәлки барлык дәрәҗәдәге мәгариф системасына (федераль) билгеле бер җитди таләпләр куела. Таләпләрнең өч төркеме билгеләнгән: 1) базис укыту планының төзелешенә һәм эчтәлегенә; 2) аны үзләштерү нәтиҗәләренә; 3) укыту программаларын гамәлгә ашыру шартларына таләпләр.

Төп укыту программаларын үзләштерү нәтиҗәләренә таләпләр — һәр укучының гыйлем туплауда ирешкән казанышларын шәхси бәяләү критерийлары ул. Шул нигездә укучының танып-белү, универсал белем туплау (операциональ) эшчәнлегеннән, мәгариф системасының барлык дәрәҗәләрендә (республика, төбәк, аерым мәгариф учреждениеләрендә) эшчәнлекнең нәтиҗәлелеген интеграль бәяләүдән гыйбарәт. Нәтиҗәләргә таләпләр — гомуми белем программаларының барлык төрләренең состав өлеше. Алар шәхси, эшчәнлекнең гомумиләштерелгән ысуллары (метапредмет) һәм фәнне өйрәнү нәтиҗәләрен үз эченә ала.

Метапредмет нәтиҗәләренә стандартларда универсал уку эшчәнлеге дип билгеләнгән гомумиләштерелгән эшчәнлек ысуллары кертелә. Алар, уку-укыту кысаларында гына куллану белән бергә, кеше эшчәнлегенең төрле өлкәләрендә танып-белү яки гамәли мәсьәләләрне хәл иткәндә файдаланылырга мөмкин.

Яңа стандартта укыту күнекмәләре ике зур блокка — универсал блокка һәм фән блогына бүленгән. Универсал уку эшчәнлеге термины педагогикада бүген кулланыла торган гомуми уку күнекмәләрен, гомуми танып-белү, фәнне өстәмә өйрәнү эшчәнлеген алыштыра.

Яңа стандартларны төзүчеләр аларны дүрт блокка —шәхси, регулятив, танып-белү һәм коммуникатив блокка берләштергән.

Шәхси эшчәнлек баланың тормыш кыйммәтләрен, әхлакый һәм мораль нормаларны аңлавын һәм кабул итүен, аның әйләнә-тирәсендәге барлык нәрсәгә шәхси карашы формалашуны аңлауга юнәлтелгән.

Регулятив эшчәнлек танып-белү процессы белән идарә итәргә булыша. Алар гыйлем туплау мәсьәләсен кабул итү күнекмәсен, билгеле бер эшчәнлекне оештыруны планлаштыру, тикшерү, үзгәрешләр кертүне, үтәлгән эшнең уңышлылыгына бәя бирүне үз эченә ала.

Танып-белү эшчәнлеге тиешле мәгълүматны эзләү һәм анализлауны, хәл итү ысулларын һәм алымнарын модельләштерүне һәм куллануны тәэмин итә.

Коммуникатив эшчәнлек хезмәттәшлекне оештыруга һәм гамәлгә ашыруга юнәлтелгән. Ул партнерны тыңлый һәм аңлый белүдән, мәгълүматны тулы һәм төгәл кабул итә һәм тапшыра, үзеңнең эш-хәрәкәтеңне партнер эш-хәрәкәте белән чагыштыра белүне үз эченә ала.

**Укучының белем дәрәҗәсенә таләпләр**

1. Татар теленең төп фонетик үзенчәлекләрен, татар теленә хас булган фонемаларның дөрес әйтелешен гамәли үзләштерү.
2. Татар телендә сүз басымын дөрес куя белү.
3. ТЫҢЛАП АҢЛАУ эшчәнлегендә текстның төп эчтәлеген аңлап укытучының сорауларына җавап бирү, бирелгән җөмләләр арасында эчтәлеккә туры килгәнен табып әйтү.
4. ДИАЛОГИК СӨЙЛӘМдә орфоэпик, лексик-грамматик нормаларны саклап, текстның төп эчтәлеге буенча әңгәмә кору, бирелгән диалогка охшаш диалог төзи белү.
5. МОНОЛОГИК СӨЙЛӘМдә сюжетлы рәсемнәр буенча хикәя төзеп сөйләү.
6. УКУ. Текстларны сәнгатьле, аңлап уку һәм сәнгатьле аңлап укуга үзлегеңнән әзерләнү.

Г омумбелем күнекмәләрен бәяләүнең критерийлары һәм нормалары

Укучыларның белем һәм күнекмәләре тикшерү эшен системалы үткәрү максатыннан, чирек башындагы агымдагы, тематик, йомгаклау характерындагы тикшерү эшләре үткәрелә.

Программада әйтелгәнчә, укучыларның тыңлап аңлау, сөйләү, уку, язу һәм язма сөйләм күнекмәләрен үстерү, яъни коммуникатив компетенцияләрен формалаштыру, һәм шулай укучыларның татар теленең фонетик, лексик, грамматик нигезләрен гамәли үзләштерүе- төп максат итеп куела.Тикшерү эшләренең төрләре шушы максатлардан чыгып сайлана.

Тыңлап аңлау күнекмәләрен тикшерү өчен биремнәр: тыңланган текстның эчтәлеге буенча сорауларга телдән җавап бирү; бирелгән җөмләләр арасыннан эчтәлеккә туры килгәне сайлап алу һ.б. Диалогик сөйләм күнекмәләрен тикшерү өчен биремнәр: рәсемнәргә карата сорау кую; куелган сорауларга җавап бирү; Монологик сөйләм буенча: предметны,(табигатьне, кешеләрне һ.б.)тасвирлау; лексик тема буенча кечкенә хикәя төзү; укылган текстның эчтәлеген сөйләү; Уку күнекмәләре буенча: татар алфавиты хәрефләрен таный белү һәм алар белән белдергән авазларның әйтелешен гамәли үзләштерү; таләп ителгән текстны сәнгатьле итеп, тиешле тизлектә кычкырып уку; текстны аңлап, эчтән уку; текст буенча куелган сорауларга җавап бирү; Язу һәм язма сөйләм күнекмәләрен тикшерү өчен биремнәр: аерым сүзләрне, җөмләләрне, бәйләнешле текстны үзгәрешсез күчереп язу; әйтелеше белән язылышы арасында аерма булмаган сүзләрне ишетеп язу; җөмләне баш хәре белән башлап, ахырында нокта, өндәү яки сорау билгесе куеп язу.

Укуны бәяләү.

***Укучыларның 1 минутка уку тизлеге түбәндәгечә бәяләнә:***

| *Сыйныфлар* | *"5"* | *"4"* | *"3"* | "2" |
|---|---|---|---|---|
| *I* | *10* | | | |
| II | 40-50 | 40-50 | 30-40 | >25-35 |
| III | 60-75 | 55-70 | 50-65 | 45-50 |
| IV | 85-95 | 80-90 | 75-85 | 70 |

**3 нче сыйныф ахырына укучы:**

- текcттагы вакыйга яки төп персонаж буенча аңа исем таба белергә;
- укытучының соравына текcттагы вакыйга яки эпизод белән җавап бирә белергә;
- текстның төп фикерен үзе билгели алырга;
- берничә текстны темасы буенча берләштерә белергә;
- укылган бүлеккә план төзи белергә тиеш.

Укытуны материаль-техник һәм мәгълүмати яктан тәэмин итү.

Әдәби укуны өйрәткәндә, түбәндәге материаль-техник чаралардан файдаланыла:

- күрсәтмә әсбаплар;
- белешмә материаллар;
- аудио һәм видео әсбаплар;
- мультимедиа укыту программалары;
- компьютер программалары; интерактив программалар; татар сайтлары; (Ье1ет.т; 1а1ап1е.ог§.сот)

| № | Дәрес темасы. | Сәг сан ы | Көтелгән нәтиҗәләр | Укучылар эшчәнлеге | Үтәлү вакыты | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | **метапредмет** | **предмет** | **шәхеси** | | **План** | **Факт** |
| 1 | М.Гафури “Балалар эше”“Балалар һәм китап” | 1 | Мөстәкыйль фикер йөртү күнекмәләрен үстерү. | Әсәрне уку, сөйләм телен үстерү. | Китап укуга кызыксыну уяту | М.Гафуриның тормышы турында кыскача мәгълүмат бирү, әсәрләренең эчтәлеге белән таныштыру. | 06.09 | 06.09 |
| 2 | Г.Тукай “Кызыклы шәкерт” Г.Морат “Туган тел | 1 | Аңлап укый белү | Шигырьне сәнгатьле итеп рольләргә бүлеп уку,эчтәлеген сөйләү | Шигырь укуга кызыксыну тәрбияләү | Г.Тукай иҗаты турында төшенчә. | 15.09 | 15.09 |
| 3 | И.В.Рафиков. ”Әй,туган тел!”картинасы.өстендә эш | 1 | Тасвирлау һәм хикәяләү элементларын кертеп, лексик тема буенча эзлекле сөйли белү | Рәссам И.В.Рафиков картинасы турында белү, сөйләм телен үстерү | Туган телгә ихтирам тәрбияләү. | Рәсем буенча сөйләшү,биремнәр эшләү. | 22.09 | 22.09 |
| 4 | Р.Гыйззәтуллин ”Кечкенә Ринат”. Үзеңне тикшер | 1 | Геройларга бәяләмә бирү,чагыштыру. | Укылган текстның эчтәлеген кыскача сөйли белү. | Кешеләргә бәхет яки хурлык китерүче сәбәпләрне ачыклау | Укытучы сүзе, сүзлек өстендә эш. | 26.09 | 26.10 |
| 5 | Табышмак- зиһен ачкычы. Нинди табышмаклар була? | 1 | Халык авыз иҗатын тарих белән бәйләп өйрәнү. | Халык авыз иҗатын гомуми күзаллау. | Халык авыз иҗаты әсәрләре белән | Татар халык авыз иҗаты турында төшенчә. | 06.10 | 06..10 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | кызыксыну. | | | |
| 6 | Әкият эзләре буйлап. “Бүре,кәҗә,кәбестә. | 1 | Парлап һәм кушма эшләү | Әкиятне сәнгатьле уку, бәйләнешле сөйләм күнекмәләре булдыру | Әкият укуга кызыксыну тәрбияләү | Эчтәлек белән таныштыру. Әңгәмә, сорауларга җавап бирү. | 13.10 | 13.10 |
| 7 | ”Кем җиңүче?”. Үзеңне тикшер | 1 | Үзләштерелгән күнекмәләргә үз мөнәсәбәтен белдерү | Туганлык хисе,юл куя белү турында сөйләшү | Әкият укуга кызыксыну тәрбияләү | Уку, эчтәлеге буенча фикер алышу. | 20.10 | 20.10 |
| 8 | “Комсыз эт.“Умарта корты вә чебеннәр” | 1 | Төрле чыганаклардан кирәкле мәгълүмат таба белү. | Мәсәл жанры турында белемне ныгыту. | Туган теленә мәхәббәт тәрбияләү. | Мәсәл жанры турында төшенчә, эчтәлеген аңлату. | 27.10 | 27.10 |
| 9 | ”Әтәч белән күке.”. Үзеңне тикшер | 1 | Уңай һәм тискәре сыйфатларны билгели алу, чагыштырып нәтиҗә ясый белү. | Г.Тукай әсәрләрен уку һәм истә калдыру. | Балаларда кешелеклелек, намуслылык, гаделлек сыйфатларына карата хөрмәт тәрбияләү | Сүзлек өстендә эш, уку, мәсәлдән мәкальләр табу. | 10.11 | |
| 10 | И.Солтан ”Көз” Д.Гайнетдинова ”Көзге урман | 1 | Аралаша белү сәләтен үстерү | Көзге табигатьтәге үзгәрешләрне күзәтергә өйрәнү | Табигатькә мәхәббәт тәрбияләү | Әңгәмә, рәсемнәрне күзәтү. | 17.11 | |
| 11 | Ф .Яруллин”Көзге табын”. Чагыштыру | 1 | Әдәби әсәрне ишетеп кабул итү. | Сорауга җавап бирү, мөстәкыйль | Туган якка карата ярату хисе тәрбияләү | Көзге уңыш,көз турында сөйләм төзү. | 24.11 | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | фикер йөртү | | | | |
| 12 | Л.И.Левитан.Урман күле. Пейзаж | 1 | Рәсем сәнгате белән әдәбият бәйләнеше. | Рәсем буенча хикәя төзү, көзге табигатьне күрә белергә өйрәнү. | Табигать матурлыгын күрергә өйрәтү, экологик тәрбия бирү | Картина буенча бәйләнешле сөйләм телен үстерү,нәтиҗәләр чыгару,анализ ясау. | 08.12 | |
| 13 | Б.Рәхмәт.Ватан.Р.Вәлиева”Иң матур җир.” | 1 | Аңлап укый белү. Төп фикер, сәнгатьле уку. | Нәрсә соң ул туган як?Туган як турында сөйли белү | Татарстан Республикасы, аның казанышлары белән горурлану хисләре тәрбияләү. | Текст өстендә эш, биремнәрне үтәү. | 15.12 | |
| 14 | Ф.Хөсни “Беренче кар” | 1 | Табигатькә карата күзәтүчәнлек тәрбияләү, һава торышының үзгәрешен аңлау. | Кышкы табигать бизәкләре турында төшенчә, кыш ел фасылына характеристика бирә белү. | Табигать белән кызыксыну хисе тәрбияләү | Әңгәмә, сорауларга җавап бирү, рәсемнәр күзәтү. | 21.12 | |
| 15 | В.Бианки ”Куян,көртлек һәм кыш бабай” | 1 | Укытучының күрсәтмәләрен үти белү, төп фикерне таба белү | Кышын кошлар һәм җәнлекләр. Аларга ярдәм итү, саклау турында сөйли белү | Әдәби укуга кызыксыну уяту | Әкият жанры турында төшенчә, эчтәлеген аңлату. | 29.12 | |
| 16 | А.Әхмәт”Кышкы матурлык”Г.Тукай ”Җир йокысы” | 1 | Мөстәкыйль фикер йөртү күнекмәсе, текстның эчтәлеген аңлап, үз фикереңне | Кышкы табигать бизәкләре турында сөйли белү | Кышкы табигатькә кызыксыну уяту | Эчтәлек белән таныштыру. Сәнгатьле уку, анализлау,нәтиҗә | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | әйтә белү. | | | ләр чыгару. | | |
| 17 | Ә.Ерикәй”Кыш”Р.Миңнуллин.Чыршы әйләнәсендә. | 1 | Мөстәкыйль фикер йөртү күнекмәләрен формалаштыру. | Укылган текстның эчтәлеге буенча фикер алышуда катнашу. | | Әсәрнең эчтәлеге белән танышу. | | |
| 18 | В.Хәйруллина. Әдәп. А.Әхмәт.Малайлар аңламадылар | 1 | Парлап һәм кушма эшләү | Сәнгатьле уку, бәйләнешле сөйләм күнекмәләре булдыру | укуга кызыксыну тәрбияләү | Эчтәлек белән таныштыру. Әңгәмә, сорауларга җавап бирү. | | |
| 19 | З.Әхмәров. Шулай да булгалый | 1 | Мөстәкыйль нәтиҗә ясау күнекмәсе булдыру | Бирелгән текст буенча план төзи белү. | Укучыларда әдәби укуны тирәнтен өйрәнү теләген үстерү | Эчтәлек белән танышу. | | |
| 20 | Н.Каштанов Йөнтәс песи баласы. | 1 | Сөйләм үстерү, сәнгатьле уку күнекмәләрен булдыру. | Укылган әсәрләрне дәлилләү. | Хайваннарга сакчыл караш тәрбияләү. | Үткән темалар буенча сөйләшү. | | |
| 21 | Р.Гыйззәтуллин. Көтелмәгән сорау. Үзеңне тикшер | 1 | Аңлап укый белү | Тотрыклы сүзтезмәләр өстендә эш. | Ана телен үзләштерү теләге булдыру | Әсәрнең эчтәлеге белән танышу. Сүзлек белән эш, парлап сөйләшү, | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | мөстәкыйль укып, төп мәгълүматны аңлау. | | |
| 22 | Р.Вәлиева.Туган көндә.. Ә.Хәсәнов. Сез ни әйтерсез икән | 1 | Мөстәкыйль нәтиҗә ясау күнекмәсе булдыру | Бирелгән текст буенча план төзи белү. | Укучыларда әдәби укуны тирәнтен өйрәнү теләген үстерү | Эчтәлек белән танышу. | | |
| 23 | А.Алиш. Утлы йомырка | 1 | Яхшылык һәм яманлык төшенчәләрен аңлату. | Геройларның портретын, холкын, эш-гамәлләрен ачу | Тормышта урыныңны табуга дөрес караш тәрбияләү | Хикәяне сәнгатьле уку, рәсем өстендә эш, сүзлек эше | | |
| 24 | Р.Батулла. Карурманга бара Мөбарәк | 1 | Мөстәкыйль нәтиҗә ясау күнекмәсе булдыру | Бирелгән текст буенча план төзи белү. | Укучыларда әдәби укуны тирәнтен өйрәнү теләген үстерү | Эчтәлек белән танышу. | | |
| 25 | Ф.Яруллин.Кояштагы тап | 1 | Җаваплылык хисләре, һәр эшне ахырына кадәр җиткерә белү теләге тәрбияләү | Ф.Яруллин турында белешмә бирү,"Кояштагы | Әниләргә карата шәфкатьлелек, хөрмәт хисләрен үстерү. | Ана һәм бала мөнәсәбәт, әсәрнең төп фикерен табу. | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | тап” хикәясен уку. | | | | |
| 26 | М.Җәлил. Себерке әкияте. Үзеңне тикшер | 1 | Сөйләм үстерү, сәнгатьле уку күнекмәләрен булдыру. | Әдәплелек төшенчәсен киңәйтеп аңлау | Укучыларда әдәби укуны тирәнтен өйрәнү теләген үстерү | Табигатькә ярдәм итү турында әңгәмә. | | |
| 27 | Ш.Галиев “Җиргә язны кем китерә” Дәрдемәнд ”Кояшның нурлары” | 1 | Парлап һәм күмәк эшләү | Язгы кояштан кошлар дөньясының җанлануы турында сөйләү | Табигать матурлыгын күрергә өйрәтү, экологик тәрбия бирү | Уку, әңгәмә, бирем нәрне утәү, рәсем ясау. Сәнгатьле уку өстендә эшләү,әңгәмә,сорауларга җавап бирү. | | |
| 28 | Л.Ә.Фәттахов ”Әни күрмәгәндә” картинасы. | 1 | Күзәтү ясап, нәтиҗә ясый белү | Су анасына характерестика бирү. | Укучыларда әкиятләргә мәхәббәт тәрбияләү, сөйләм культурасын үстерү | Рәсем буенча хикәя төзү, табигатьне күрә белергә өйрәнү. | | |
| 29 | .”Гөлчәчәк” әкияте | 1 | Уңай һәм тискәре сыйфатларны билгели алу, чагыштырып нәтиҗә ясый белү. | Әкият турында белешмә.Әкият белән танышу | Укучыларда әкиятләргә мәхәббәт тәрбияләү, сөйләм культурасын үстерү | Алган белем һәм күнекмәләрен ныгыту. | | |
| 30 | ”Тату туганнар” әкияте | 1 | Мөстәкыйль фикер йөртү. | Язучылар иҗатына мифик геройларкерүе | Аралашу культурасы тәрбияләү, | Ана һәм бала мөнәсәбәте, әсәрнең төп | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | белән таныштыру. | экологик тәрбия | фикерен табу. | | |
| 31 | Г.Тукай “Су анасы” | 1 | Мөстәкыйль фикер йөртү. | Язучылар иҗатына мифик геройларкерүе белән таныштыру. | Аралашу культурасы тәрбияләү, экологик тәрбия | Ана һәм бала мөнәсәбәте, әсәрнең төп фикерен табу. | | |
| 32 | Х.Халиков ”Мыекмай” | 1 | Шигъри әсәрне җиңел истә калдыру ысулларын өйрәнү. | Дуслык турында шигырьне уку, сөйләм телен үстерү | Дуслыкның кеше өчен мөһимлеген аңлату | Әсәрнең эчтәлеге белән таныштыру. | | |
| 33 | Х.Халиков ”Хәрәкәттә-бәрәкәт С .Әхмәтҗанова ”Үрнәк алыйк” | 1 | Сәламәт яшәү рәвеше турында мәгълүмат бирү. | Сәнгатьле уку күнекмәләре үстерү. | Әхлак тәрбиясе бирү, сәламәт яшәү рәвеше турында мәгълүмат бирү. | Эчтәлек белән таныштыру,план төзү | | |
| 34 | Үткәннәрне кабатлау. Сорау-җавап уены | 1 | Өйрәнгәннәрне гомумиләштерә, нәтиҗә ясый белү. | Әдәби әсәрләрне, теоретик төшенчәләрне аңлап истә калдыру. | Әдәбият белән кызыксындыру, тормыш белән бәйләнеше аңлау. | Үткәннәргә йомгак ясау. | | |